СЫНАЛЫР ЧАК

Татарстанда 16 меңгә якын укучы рус теленнән имтихан тапшырды

> 2

ИМАН ЙОРТЫ

Түбән Якедә Мамадыш районындагы 62 нче мәчет ачылды

> 3

ТИКТОРМАС ӘБИ

82 яшьлек Венера Гыйлаҗева яшьлектә күрмәгәнне бүгеи татып калырга тырыша

> 4

ЯҢГЫРЛЫ «КАРАВОН»

Лаеш районындагы мәдәни бәйрәм 30 нчы тапкыр узды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 75 (28848) | Сишәмбе | 31 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

УТЫРЫП ЙӨРҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Бик кирәк булса гына аласы. Якын арада машинамны алыштырыйммы, юкмы дип баш ваткан кешеләргә белгечләр шушы кагыйдәне истә тотарга куша. Альпсатарлар исә бүген кулай бәядән машина эләктереп калу өчен иң кулай вакыт дип саный. Ни эшләргә?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Булганда эләктереп кал

Рәсми саннарга караганда, апрель аенда Россиядә сатылган яңа машиналар саны 78,5 процентка азайган. Белгечләр моны килеп туган вазгыять «җимеше» дип атый. Яшерен-батырын түгел, бүген автосалондагы машина бәяләре янына якын килә торган түгел. Аларның хаклары әле дә булса үзгәрешсез кала бирә. Шуңа күпләр тотылган машиналарга өстенлек бирергә тырыша, ди белгечләр.

Машиналар алып-сату белән шөгыльләнүче Рамил Фәйзуллин сүзләренә караганда, тотылган машина хаклары апрель аенда ук төшә башлаган. «Кайбер машиналар 50–200 мең сумга очсызланды. Әйтик, әле кайчан гына 1 миллион сум чамасы торган 2014 елгы машинаны бүген 600–700 мең сумга алып була», – ди ул.

Рамил Фәйзуллин сүзләренә караганда, бүген тотылган машина сатып алучылар күбрәк аның техник яктан төзек булуына, бу машинаның «тәрбияләп тору»ның күпмегә төшәчәгенә игътибар итә. Ник дигәндә, хәзерге вазгыятьтә машинаңа кирәкле запчасть табу да баш бәласенә әверелеп бара. Булганын да баш бәсенә аласы.

– Тотылган машинага кызыккан кеше үзенә кирәкле машинаны хәзер шактый кулай бәядән эләктереп кала ала. Ник дигәндә, алга таба ни буласын беркем белми. Әммә машина бәяләре, һәрхәлдә, моннан да ары арзанаймаячак инде. Ә менә базарда яхшы машина табу торган саен авырлашырга мөмкин. Сайлау мөмкинлеге булганда, эләктереп калырга кирәк, – ди Рамил.

Искесе дә ярап тора

«Автостат» аналитик үзәге белгече Азат Тимерханов сүзләренә караганда, соңгы арада тотылган машиналар, дөрестән дә, очсызлана башлаган. Автосалоннардагы машина бәяләре исә үзгәрешсез калган.

– Бүген житештерүчеләр машинага бәя арттырудан туктады. «Тимер ат» бәяләренең иң котырган чоры март аена туры килде. Билгеле булганча, махсус операция башлану белән сум очсызланды. Шуңа бәйле рәвештә житештерүчеләр дә машина бәяләрен күтәрә башлады. Нәтиҗәдә март аенда яңа машиналар уртача 35–45 процентка кыйммәтләнде. Апрель аенда инде бу шаукым тынды. Бу айда бәяләрне мартта күтәрергә өлгермәүчеләр арттырды. Майда инде житештерүчеләр яңа машина бәяләрен күтәрүдән тукталды, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Белгеч китергән мәгълүматларга караганда, мартта 800000 яңа машина сатылган булса, апрельдә бу сан 27–28 меңгә калган. Бу – яз уртасында автосалондагы яңа машиналар өч тапкыр азрак сатылган дигән сүз. Май аенда тагын да азрак булыр дип фаразлый ул. Билгеле сәбәпләр аркасында, күп кенә житештерүчеләр Россия базарыннан китте. Өстәвенә соңгы арада үзебездә дә машиналар азрак житештерелә башлаган. Моңысы һаман да шул детальләр җитмәүгә барып тоташа. Аннары кешеләр үзләре дә ике-өч тапкыр кыйммәтрәк бәядән машина сатып алырга теләми, билгеле.

– Тотылган машиналар базарында вазгыять башкачарак. Башта алар да бик нык кыйммәтләнде. 24 февральдән башлап күпләр машина сату турындагы игъланнарын кире ала башлады. Машинаны сатучын сатар да, аннан соң нишләр? Күпләр әнә шулай дип баш ватты, искә машинасында йөреп торырга булды. Май аенда исә машина сату турында игъланнар кабат күренә башлады, – ди Азат Тимерханов. – Бер ай эчендә кулдан машина сату турындагы игъланнар саны 30–40 процентка арткан. Шуңа бәйле рәвештә бәяләр дә бераз төшкән кебек булды. Тәгәрәк әйтсәк, май аенда Россиядә тотылган машиналар уртача 3–4 процентка очсызланды. Артык зур сан түгел, билгеле. Ләкин кимүе белән игътибарга лаек. Алга таба тотылган машина хаклары белән ни булачагын да фаразлау кыен.

Белгеч җәй көне машина базарында апрель – майдагы кебек вазгыять саклаңыр дип фаразлый. Якын арада машинасын алыштырырга хыялланган кешеләргә исә валюта курсын күзәтеп барырга киңәш итә. Ул әле дә булса тотрыклы түгел. Шуңа күрә белгеч якын киләчәктә яңа машина бәяләре төшәр дип өметләнергә кирәкми, дигән фикердә.

– Бүген машинаны бик кирәк булган очракта гына алырга кирәк. Йөреп торырга «тимер ат»ың булса, артык акчаңны аны ремонтлауга тотып, шушы машинаң белән тагын бер-ике ел йөреп торсаң яхшырак. Ник дигәндә, машина базарында алга таба ниләр буласын фаразлау кыен. Хәтта көзгә таба вазгыятьнең ничек булачагын да чамалап булмый, – ди Азат Тимерханов.

Тотылган иң популяр машиналар (өч еллык)

Машина	Бер ел эчендә күпмегә кыйммәтләнгән (процентларда)	Хәзер уртача бәясе
Lada Granta	50	715 000
Hyundai Solaris	53	1,4 млн
Lada Vesta	46	995 000
Kio Rio	50	1,4 млн
Toyota Camry	50	3,2 млн

Дүрт миллионнан артканбыз

Халык санын алуның беренче нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда 4 миллион 5 мең кеше яши. Шуның 3 миллионнан артыграгы – шәһәрдә. 931 мең кеше авылда гомер кичерә, дип хәбәр итә Росстат.

2010 елгы җанисәп алу белән чагыштырганда, республикада яшәүчеләр саны 5,8 процентка арткан. 11 ел элгәрәк бездә 3,8 миллион чамасы кеше яшәгән булган. Татарстан төбәкләрдәге халык саны буенча, элеккечә үк, Мәскәү, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург, Краснодар крае, Свердловск, Ростов өлкәләре, Башкортстаннан соң 8 нче урынны били. Илдә яшәүчеләрнең өчтән бер өлеше шушы 8 төбәккә туры килә. Алдагы җанисәп алу белән чагыштырганда, халык саны нибары 28 төбәктә генә арткан. Калганнарында кимегән. Мәскәүдә, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендә, Краснодар краенда яшәүчеләр аеруча нык ишәйгән.

Илдә вакытлыча яшәүчеләр (350 мең кеше) дә исәпләнгән. Мондыйлар Мәскәүдә, Мәскәү өлкәсе, Приморье крае, Амур өлкәсе һәм Татарстанда барыннан да күбрәк теркәлгән. Росстат билгеләп үткәнчә, шәһәрләшү дәвам иткән: халыкның 75 проценты – шәһәрләрдә, 25 проценты авылларда яши. Шунысын да әйтеп үтик: соңгы мәгълүматлар буенча тагын дүрт шәһәр – Краснодар, Красноярск, Пермь һәм Воронеж «миллионер» шәһәрләр исемлеген тулыландырган. Хәзер илдә халык саны 1әр миллионнан артып киткән 16 шәһәр бар. Ил халкының дүрттән бер өлеше чамасы шушы шәһәрләрдә яши.

Күбрәк ял итәчәкләр

Җәйге каникул чорында Татарстан лагерьларында 180 меңнән бала ял итә алачак. Узган елдагыга караганда дүрттән бер өлешкә күбрәк бу. Яшьләр эшләре министрлыгының беренче урынбасары Ринат Садыйков әйтүенчә, барлыгы 1,6 меңнән артык ял объекты эшләячәк. Болар – гадәттәге лагерьлар, палатка, санаторий-курорт, хезмәт һәм ял, мәктәп яны лагерьлары, шулай ук Кырым һәм Краснодар крае лагерьлары. Ял итүчеләр саны узган елдагы белән чагыштырганда 25 процентка арткан. Сәбәбе – Роспотребнадзор идарәсенең коронавируска бәйле чикләүләрне алуы (узган елда лагерьларны 75 процентка гына тутырырга мөмкин булган). Лагерьда ял итүчеләр театрлар, күргәзмә, кинотеатр, бассейннарга һәм башка шәһәр объектларына да йөрергә мөмкин. Моннан тыш 860лап мәктәп яны лагере эшләячәк. Аларда 57 меңгә якын башлангыч сыйныф укучысының ял итүе күздә тотыла. Татарстанда яшәүче халыкларның телен, мәдәниятен, традицияләрен саклау һәм үстерүгә юнәлеш тотучы профильле сменаларда исә 2010 кеше ял итәчәк. Быел шундый 9 смена булдырыла.

Бала өчен эшлисе

Әгерҗе районында 34 яшьлек хатын-кызга карата хөкем карары чыгарылган. Татарстан прокуроры өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев «Татар-информ» хәбәрчесенә белдергәнчә, ул балаларын карау өчен акча түләмәгән. Судта билгеләнгәнчә, ана үзенең 4 баласы өчен алимент түләргә тиеш булган. Әммә узган елның декабреннән быел мартка кадәр сабыйларына матди ярдәм күрсәтмәгән. Моңа кадәр дә шундый ук гаебе өчен административ җаваплылыкка тартылган булган. Ул чагында 10 тәүлеккә сак астына алынган.

Ваемсыз ананың алимент буенча гомуми бурычы 2 миллион сумга җиткән. Суд аны алты айга мәҗбүри эшләргә хөкем иткән. Хезмәт хакының 5 проценты дәүләт файдасына тотып калыначак.

Көн үзәгендә

Җәйдә акча арта

Россия Премьер-министры Михаил Мишустин минималь хезмәт хакы (МРОТ) һәм яшәү минимумы күләмен, эшләмәүче пенсионерларга пенсияне арттыру турындагы карарга кул куйды.

Хөкүмәт җитәкчесе әйтүенчә, әлеге максатларга федераль бюджеттан 500 млрд сумнан артык акча бүлеп биреләчәк. Матди ярдәм 50 млн кешегә эләгәчәк.

Михаил Мишустин индексация нәтиҗәсендә кемнең күпме акча алачагын да хәбәр итте.

Әйтик, эшләмәүче пенсионерларның айлык пенсиясе, уртача алганда, 19 мең сумнан артып китәчәк. Минималь хезмәт хакы күләме исә 15,2 мең сумнан күбрәк булачак. Бу исә 4 миллионнан артык хезмәткәрнең хезмәт хакын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, яшәү минимумы, ә аның белән бергә керемнәре түбән булган гаиләләрдәге 3 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балаларга ай саен бирелә торган пособиеләр күләме дә артачак.

– Ярдәм кирәк булган кешеләргә Хөкүмәт булышачак, – диде Михаил Мишустин.

Сүз уңаеннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов халыкка өстәмә ярдәм итү өчен төбәк бюджетыннан тиешле күләмдә акча әзерләргә кушты. Бу хакта ул «шимбә киңәшмәсе»ндә әйтте.

– Россия Президенты Владимир Путин Дәүләт Советы утырышында өстәмә социаль ярдәм чаралары турында игълан итте. Бу кайбер категория кешеләрнең керемнәрен үстерү мөмкинлеген бирәчәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Президент искәрткәнчә, Пенсия фонды бүлекләренә пенсияләрне тиз арада яңадан исәпләп, халыкка түләргә кирәк булачак. Июнь – июльдә котеләчәк матди үзгәрешләр өчен республика бюджетыннан өстәмә акча таләп ителәчәк.

Моннан тыш, Владимир Путинның төбәкләр хакимиятләренә хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә кирәкле барлык социаль ярдәм күрсәтергә дә кушкан иде. «Район-шәһәр хакимиятләре башлыкларына, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә, махсус хәрби операциядә һәлак булган яки яраланган хәрбиләрнең гаиләләренә тиз арада ярдәм итүне контрольдә тотарга кирәк», – диде бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов.

Сүзгә-сүз

Дмитрий АФАНАСЬЕВ, Россия фән һәм югары белем бирү министры урынбасары:

Болонья процессыннан баш тарту 1991 елга кадәр булган системага кире кайту дигән сүз түгел. Ул вакыттагы өстенлекләрне дә, соңгы елларда халыкара хезмәттәшлек шартларында тупланган тәҗрибәне дә исәпкә алган илкүләм система булдыру турында сүз бара.

(Иҗади вуз ректорлары советы утырышында сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – ЯЗГЫ ЧӘЧҮ

Республикада язгы чәчү эшләре тәмамланып килә. 30 майга булган мәгълүматларга караганда, 1,8 миллион гектарның 1,6 миллионнан артыгы чәчелгән. Бу – планның 88 проценты. Эшне 5 июньгә төгәлләргә ниятлиләр.

- Бодай – 432,3 мең га....................89%
- Арпа – 445,4 мең га....................98%
- Борчак – 53,3 мең га....................98%
- Шикәр чөгендере – 49,6 мең га....100%
- Бәрәңге – 4,7 мең га....................56%

Җылы көннәр башлана

Бу атнада Татарстанда +27 градуска кадәр җылыта. Башлыча аяз һава көтелә. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, 1 һәм 2 июньдә көндезге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы +21...+27 градус күрсәтәчәк. Җомга – 3 июнь һәм шимбә – 4 июньдә, көнбатыштан циклон үтеп керү сәбәпле, урыны белән кыска вакытлы яшенле яңгырлар булырга мөмкин. Көндез +21...+26 градус. Төнлә дә җылы: +11...+16.

Илдар Мөхәммәтҗанов



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТӨРЕКЧӘ ДӨНЬЯ ЯУЛАУ

Дөньяның мәгълүмат чаралары, Украинада бара торган махсус хәрби операция масштаблы ачлыкка һәм зур фетнәгә китерә, дип чаң сугалар. Бөртекле ашлык кризисы Мисырда бүген үк революция алды вазгыяте тудырды дип әйтүчеләр бар. Эш шунда: йөз миллионнан артык кеше яшәүче бу Төньяк Африка дәүләте – ашлык импортлаучы иң зур илләрнең берсе, шуңа карамастан, мисырлылар ипи ашарга бик ярата. Җир шарының башка төбәкләренә караганда анда икмәкне уртача өч тапкыр күбрәк кулланалар. Моңа икмәкнең бушка диярлек сатылуы этәргеч бирәдер, мөгаен. Субсидияләнгәч, бер ләвәш безнең акча белән бары тик бер сум гына тора. Шундый арзанлы ризыкны ил халкының өчтән дүрте (72 миллион кеше) файдалана. Ашлыкка бәянең чамасыз күтәрелүе Мисыр хакимиятләрен дилемма алдына куйды: я бәяне ирекккә җибәрәсең, я бушлай ашаучылар санын кискен – 20 миллион кешегә кадәр киметәсең. Икесе дә зур фетнәгә китерүе бар.

Бәяләр бер Мисырда гына түгел, нык үсешкә ирешкән бай илләрдә дә болытларга таба омтыла. Британ газетасы The Guardian илдә электр һәм җылылык белән бергә азык-төлеккә дә бәяләрнең зур сикерешенә борчылу белдерә. Соңгы сигез ай эчендә тавык ите хакы ике тапкыр сикергән.

Менә шундый катлаулы шартларда дәүләтләр йогынты сфераларын бүлешү буенча тиңсез көрәш алып бара. Төркия традицион рәвештә Азәрбайҗанга хәрби ярдәмен арттыра, Гыйракта яңа зур хәрби операция башларга җыена, Якын Көнчыгышның нефть державалары белән арасын көйли, Африкада мөстәкыйль сәясәт алып бара, Финляндия белән Швециянең НАТОга керүенә аяк чала. Соңгысын – НАТО белән бәйле вазгыятьне ул сөйләшүләр белән җайга салырга тырыша: Скандинавия дәүләтләре алдында катгый таләпләр куя. Швециянең Стратегик максатлардагы продукция экспортлау дәүләт инспекциясе рәисе Карл Эвертссон Төркиягә корал сатуга эмбаргоның бетерелүе хакында игълан итте инде. Әмма Әнкара моңа гына риза түгел, Төркиядә террорчы дип табылучыларга фин һәм швед ярдәмен туктатуны таләп итә. Мөгаен, ике ил дә ахыр чиктә төрек басымына буйсынып, компромисска бармый калмаслар.

Әрдоган үзе сыгылмалы сәясәт үткәрүнең мастер-классын күрсәтә. Үпкәләштә булган Согуд Корольлеге белән араны җайга салды. «Байрактар»лар Хиҗаз чүле өстендә оча башлаячак, аларны сатуга килешү төзелде. Төркиянең оборона эшләре министры Хулуси Акар бу юллар язылыр алдыннан гына соңгы унбиш елда беренче тапкыр Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә эш визиты белән килде. Ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр шулай ук киеренке иде, хәзер җепши башлады. Әрдоган үзе исә Азәрбайҗанга визиты вакытында Илһам Алиев белән Bayraktar AKINCI TİHA беспилотнигының корпусына имзасын салды. Baykar Makina компаниясенең иң соңгы эшләнмәсе булган бу очкыч канатлы ракеталар белән ата ала, 1350 килограммга кадәр йөк күтәрә һәм дәһшәтле хәрби көч булып санала. Әнкара аларны Бакуга сата башлады.

Төркиядә Efes 2022 дип аталган хәрби өйрәнүләр башланды. Анда 37 ил хәрбиләре катнаша. Грек хәрби көчләре бу уңайдан көчәйтелгән хәрби хәзерлек хәленә китерелде. Греклар үзләренә куркыныч яный дип саныйлар.

Россиядә

ӘНКАРА БЕЛӘН МӘҢГЕГӘ БЕРГӘ?

Төркия вакыты-вакыты белән Россия мәнфәгатьләренә каты гына басып куйгаласа да, ике ил арасында стратегик аркадашлык дәвам итә. Көньяк күрше соңгы вакытларда россиялеләр өчен бердәнбер диярлек ышанычлы гавань булып калып бара. Кара диңгез буе дәүләтендә «Мир» карталары белән түләү һәм акча алу мөмкинлеге арта, төрек кием брендлары Мәскәүне һәм башка Россия шәһәрләрен яулый башлады, «Төрек агымы» буенча Себер газын иркен кудырабыз: эмбарго да юк, чикләүләр дә көтелми. Әрдоган ике ил арасында сумнарда сәүдә итешүгә каршы түгел. Мәскәү дә төрекләр нинди валюта белән түләсә, шуңа риза.

Менә карагыз: Россиянең йогынты зонасында дип саналган Казахстан алай ук аркадашлык сакламый Мәскәү белән. Казахстан электрон хөкүмәтенең сайтында россиялеләрнең илгә «карта туризмы»н туктату турында игълан эленде. Сәбәпләре әйтелми. Әле Казаннан яисә Мәскәүдән барып, үзебезгә казах банкларының картасын ясата һәм теләсә кайсы илдә шуның белән түли, үз хисабыбызга акча күчертә ала идек. Хәзер ул мөмкинлек бетерелде. Үзебезнең карталар исә чикнең теге ягына чыгуга чүпкә әверелә. Казахстан хөкүмәтендә Европа илләреннән йөк ташучы Россия һәм Белоруссия автомобильләрен тоткарлый башлаячакларын да әйттеләр. Бу хакта Халыкара йөк ташучыларның Беларусь ассоциациясе хәбәр итә.

Төрекләр исә чикләмиләр безнең белән хезмәттәшлекне, киресенчә, җәелдерәләр. Мәскәү дә яхшылыкка яхшылык белән җавап бирә. Сүриянең төньягында башланып килүче хәрби операциягә АКШ һәм башка дәүләтләр тискәре мөнәсәбәт белдерә, Мәскәү исә хуплый. Сүз моңарчы Россия һәм Иран канаты астында булган төбәкләр хакында бара. Бу юллар язылганда, төрек гаскәрләре чик аша үтеп чыгып баралар, Россия исә төбәктән үз гаскәрләрен ала. Иордания короле Абдалла II ибн Хөсәен әль-Хашими берничә көн элек Россиянең гомумән гаскәрләрен Сүриядән чыгаруы турында белдерде. Мәскәү моны расламады да, кире дә какмады. Абдалла II малай-шалай түгел, җитди лидер, шулай булгач, аның сүзләрен ышанычлы чыганак дип кабул итәргә мөмкиндер, мөгаен. Нәрсә генә булмасын, заманча кораллар белән коралланган төрек армиясенең чик аша үтеп, Гыйфрат елгасының көнбатыш ярындагы төбәкләргә таба хәрәкәтен Россиянең тышкы эшләр министры Лавров хуплап чыгыш ясады.

Әнкара белән аркадашлык Россия өчен бүген аеруча әһәмиятле. Икътисади хәлебез бер дә ышанычлы түгел. Соңгы көннәрдә Байденның ике киңәшчесе АКШтан Согуд Гарәбстанына яшерен сөйләшүләр алып бару өчен китте дигән хәбәрләр бар. Вашингтон согудләр белән 1980 нче еллардагы уенны башлап җибәрергә тели: «кара алтын» чыгаруны арттырып, бәясен төшерергә ниятли. Россия бюджеты исә углеводородлар табышыннан гына тора диярлек хәзер. Вашингтон уены барып чыкса, хәл яман булачак…

ТАТАРСТАНДА – ЯҢА МИНИСТР

Хөкүмәттә үзгәреш

Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының яңа башлыгы, шул исәптән республиканың яңа вице-премьеры билгеле булды. Бүгеннән әлеге вазыйфаны Олег Коробченко башкарачак. Шул хакта карарны Татарстан Президенты имзалады. Премьер-министр Алексей Песошин аны министрлыкта тәкъдим итте.

Исегезгә төшереп үтик: элеккеге министр Альберт Кәримовны, Россия Хөкүмәте карары нигезендә, Россия сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары итеп билгеләделәр. Ул эшчәнлегең федераль министрлыкта дәвам итәчәк.

Министр вазыйфасына билгеләнгән Олег Коробченко тумышы белән – Белоруссиядән. Аңа 45 яшь. Икътисад, идарә һәм хокук институтында «Финанс һәм кредит» юнәлеше буенча белем алган, 2015 елда исә Россия Президенты каршындагы Россия Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең корпоратив идарә итү югары мәктәбен тәмамлаган. Үз вакытында слесарь булып эшләгән, хисапчы, баш хисапчы хезмәтен башкарган. Хәзерге көндә – «Кориб» оешмасы генераль директоры.

2019 елда Коробченко Татарстан Дәүләт Советы депутаты булып сайланды. Ул «Партия Роста»ның төбәк бүлеген җитәкли, Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча комитеты әгъзасы санала.

Олег Коробченконың вазыйфага билгеләнүе турында рәсми рәвештә Татарстан Дәүләт Советының чираттагы утырышында тәкъдим итәчәкләр. Шул көнне Олег Коробченко депутат вазыйфасыннан азат ителәчәк.

КОРОБЧЕНКО ТУРЫНДА – ФАКТЛАР

✓ Әтисе «БелАЗ» төзелешендә катнашкан, әнисе – укытучы.
✓ 1990 елда Чаллыга күченеп кайталар.
✓ Өйләнгән, биш бала тәрбияли.
✓ Олег Коробченко – меценат. Ул күп кенә мәктәп футбол командаларына, коммерциячел булмаган балалар оешмасына матди ярдәм күрсәтә.
✓ Олег Коробченко спортка да битараф түгел: ул байдарка һәм каноэда ишү буенча федерация президенты.

tatarstan.ru

> Кайчагында хуҗа җиргә төшәргә, сәгать 7дә утырыш үткәрергә, барысын да җыярга, барысы да эшләсен өчен этәргеч биреп торырга да тиеш.
>
> Балаларның әти-әниләренә һәм ватаннарына хөрмәт белән каравын, башкаларны да ихтирам итүләрен телим. Шуны белсеннәр: үзеңнән әллә кем ясау кешене бәхетле итми. Табигать биргән сәләтләр белән эшеңә бирелү генә бәхет өсти.

ЫШАН ҮЗЕҢӘ ГЕНӘ...

Сыналыр чак

Керәм, тапшырам, бар да яхшы булачак! Быел бердәм дәүләт имтиханнарына килүче чыгарылыш сыйныф укучылары белемнәренә ышанган булуы белән аерылып тора. Алар бернинди ырым-шырымнарга да ышанмый, шпаргалка язуга да әллә ни игътибар бирмәгәннәр. Әллә үзләрен шулай тынычландыралар, әллә, чынлап та, мәктәп елларын бушка уздырмаганнар.

Казандагы 89 нчы мәктәптә узган рус теле сынавына укучыларның хәлләрен белешергә дип Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да килгән иде. Имтиханга 3,5 сәгать вакыт бүлеп бирелгән. Министр әйтүенчә, беренче имтиханнарда кагыйдә бозу очраклары булмаган. Дөресрәге, күзәтүчеләрнең, укучылар шпаргалка алып кергән, дип шикләнүе расланмаган. Рус теленнән имтихан ике көнгә бүленгән. Анда 16 меңнән артык кеше катнаша. Шуларның 15813е – мәктәпне быел тәмамлаучылар. Беренче көнне 94 пункт эшләсә, шуның 83е – мәктәптә, 11е авыру балалар өчен өйдә оештырылган.

– Имтиханда дулкынлану да, борчылу да була, әлбәттә. Тик борчылмаска кирәк. Белгәнне биреп була. Иң мөһиме – шпаргалка алып кермәскә! Әгәр кесәңдә күп актарына башласаң, як-ягыңа карансаң, сөйләшсәң, сине куып та чыгарырга мөмкиннәр. Кагыйдә бозарга кирәкми, – диде Илсур Һадиуллин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укучылар нинди сүзләрне язганда еш хата җибәрә? Имтиханнарга ничек әзерләнгәннәр? Гадәттә, укытучылар, имтихан тапшыра алмасаң, ишегалды себерерсең, дип куркытырга ярата. Мондый очраклар да булганмы? Егет-кызларның фикерләрен белештек.

– Өтерләр куярга өйрәндем инде, башта авыр иде. Һәр хатаны аерым кабатладык. Башта кагыйдәләрне ятладык, аннан биремнәр чиштек. БДИ сораулары авыр булыр дип уйламыйм. Быел биремнәргә бераз үзгәрешләр кертелде. Әмма сораулар мәктәп программасыннан читкә чыкмас, – ди Владислав Климин. – Артык борчылмыйм, бик яхшы әзерләндем. Рус теле – туган тел бит. Кәефем яхшы. Имтихан алдыннан ял иттем. Бәлкем, кемдер муенына саклагыч бөти тагып килгәндер. Мин бары үз көчемә генә ышанам. Һичшиксез, Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясенә укырга керерлек баллар туплармын дип өметләнәм.

Узган елларда имтихан тапшыручылардан төрле ырымнар ишеткән бар. Әйтик, уң аягындагы оекбашка 5 сум акча кыстырып, ишектән уң аяк белән атлап керергә кирәк. Бу очракта билгең дә «5ле» булачак, янәсе. Кичтән мендәр астына китап салып йокласаң да, имтиханда уңыш елмаячак. Тик быелгы укучылар мондый юк-барга ышанмауларын белдерде. Моның башка ягы да бар. Ир-егетләр генә укый торган 7 нче лицей-интернаттан килгән җитди егетләр болар. Алар инде сиңа, ышанам, дип утырмас, әлбәттә. Булат Әхмәтов, курку хисе юк, ди. Яхшы укыган чөнки. Укуын Иннополиста дәвам итәсе килә. Чит шәһәрләрдәге вузларны сайлаучыларны да тәнкыйтьләми. Кайда әйбәт, шунда укысыннар, ди.

Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан килеп укыган Мирза Шаймәрдановның исә Мәскәүгә китү исәбе дә бар. Информатика юнәлешен сайларга җыена. «Авылдан монда килүемә бер дә үкенмим, киресенчә, яңа юллар ачылды», – ди Мирза.

Лицейның тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ильяс Әхәтов та, бездә көчле егетләр генә укый, дип мактап алды. Мондый үсендереп торучылар да кирәк. «Кәефләре яхшы, без БДИны яхшы бирәбез, дип ышаналар», – ди ул.

49 нчы мәктәп укучысы Никита Плаксинның хыялы юрист булу. Рус теле җайлы бит ул, дисә дә, соңгы 4 ай буе репетитор белән шөгыльләнгән. Тарих, җәмгыять белеменнән исә ике ел буе түләүле өстәмә белем алган. «БДИ кирәкми дип уйлыйм. Укытучының күзенә карап тапшыру яхшырак дип уйлыйм. Мөгаллимнәр арасында, әзерләнмәсәң, бирә алмыйсың, дип куркытучылар да бар. Монысы инде артык», – ди Никита.

Быелгы укучылар, дулкынланам, борчылам, дисә дә, гаеп түгел. Ни өчен дигәндә, коронавирус чикләүләре сәбәпле, 9 нчы сыйныфта имтихан бирмәде алар. Шуңа күрә бу нәтиҗәләрдә дә чагылырга мөмкин.

– Быел технологияләр үзгәрде. Хәзер укучыларны аудиторияләргә кертеп утыртабыз. Биремнәрне интернеттан кәгазьгә бастырып, укучыларга өләшәбез. Шуннан соң эшләрен сканер аша чыгартып, Мәскәүгә һәм үзебездәге үзәккә җибәрәбез. Бу вакытта берәү дә коридорга да, бәдрәфкә дә чыкмый. Моңа кадәр андый технология юк иде. Әгәр рус теленнән 24 балл җыйсаң, аттестат алу өчен җитә. Әмма моның белән генә әллә кая китеп булмый. Укырга керү өчен күбрәк баллар кирәк. Медальгә дәгъва кылучылар 70тән ким балл җыймаска тиеш, – диде Илсур Һадиуллин. – Беренче имтиханнарда 2600 күзәтүче катнашты. Бөтен бүлмәләргә дә видеокүзәтү җайланмалары куелган. Балалар үзләрен тыныч тотып, белемнәрен күрсәтер дип ышанабыз. Беренче нәтиҗәләр 17 июньдә билгеле булачак.

Имтиханны тапшыра алмаучыларга аны кабат 23 июнь яки 2 июльдә тапшыру мөмкинлеге бар. Ә кагыйдә бозучылар исә тагын бер елдан соң гына кабат бирә алачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Ярату кирәк...

Авыл капкасы

«Эшнең ир-атныкы, хатын-кызныкы юк. Теләсә нинди эшне яратып башкарырга гына кирәк». Чирмешәндә яшәүче кулы һәр нәрсәгә «ятып торучы» Марат Җәббаровның тормыш девизы бу. Унике ел элек ул бытбылдык үрчетү белән шөгыльләнә башлаган.

Берничә ел элек хуҗалыгындагы кошлар 600гә җитсә, хәзер 30га гына калган.

– 600 бытбылдык асраганда азык бәясе арзанрак, аның каравы сорау юк иде. Шуңа күрә киметтем. Хәзер ихтыяҗ артты, кешеләр файдасы барлыгын аңлый башладылар, тик аның белән бергә азыгы да кыйммәткәрәк төшә. Кеременнән бигрәк, чыгымы күбрәк. Бу шөгылем күңел өчен генә, – ди ул.

Иң зур файдасы – йомыркасында. Ун баш бытбылдык көненә сигез-тугыз йомырка сала, ди. Балалар аллергиядән файдасын күрсә, өлкәннәр иммунитетларын күтәрү өчен ала. Ир-атлар сәламәтлегенә дә файдалы. Косметологиядә дә уңышлы кулланып киләләр. Тик бытбылдык йомыркасын ач карынга чи килеш эчәргә кирәк. Тәмгә бераз баллырак, шунлыктан тавыкныкына караганда җиңелрәк эчелә. Бытбылдык йомыркасы тавыкныкы шикелле бозылмый да. Озак торса, кибә генә. Аннан соң, бу кошлар тавыклар арасында еш очрый торган сальмонеллез белән дә авырмый. Бытбылбык чисталык, чиста һава ярата. Ике көн асларын чистартмасаң яки вентилятор эшләми торса, йомырка салмый башлыйлар.

Кечкенә чебешләрне инкубаторга куеп чыгара. Йомыркасы буш булмасын өчен, дүрт тавыкка бер әтәч булырга тиеш икән. Ите әйтеп бетергесез тәмле, бик йомшак, майлы була, ди.

Марат абыйларның ишегалдына килеп кергәч, андагы тәртип, пөхтәлек, чәчәкләрне күреп бер тапкыр исебез китсә, бу тәртипне үзе урнаштырып торуын белгәч, бөтенләй гаҗәпләндек.

– Хатыным белән дүрт бала тәрбияләп үстердек. Бүген дүрт оныгым бар. Хатынымны исә узган ел җирләдем. Егерме ел урын өстендә ятты ул. Авырулары күп булды. Аңа да бытбылдык йомыркасын эчердем, файдасын күрдек. Операция ясап, оча-бот буынын алыштырдылар. Хастаханәдә аякка бастыра алмадылар. Өйгә алып кайтып, массаж, физкультура ясата башладым. Шуннан соң култык таягы белән йөри башлады. Кызганыч, тора-бара башка авырулары өстәлде, бер-бер артлы инфаркт, инсульт кичерде. Аның белән бергә без дә күпне күрдек. Хатыным рәхмәтле булып китте, – дип искә алды Марат абый.

– Сез бакчачылык белән дә шөгыльләнәсез алайса? – дип сорадык әңгәмәдәшебездән, бакчадагы, ишегалдындагы тәртипкә ишарәләп.

– Юк, шөгыльләнмим. Мин бу эшне яратам гына. Зур бакчамның яртысыннан артыгына чәчәкләр утырттым. Җимеш агачларын да яратам. Бер алмагачым ноябрьгә кадәр алма бирә. Груша, ясмин, сырганак, виноград – барысы да бар. Барысын да үзем эшлим. Вакытым иркен, чөнки тәүлегенә 4 сәгать йокы җитә. Артыгы кирәкми дә, – дип елмайды ул.

Аралаша торгач, Марат абыйның аш-суга да оста булуы ачыкланды. Тортын да пешерә, төрле кабымлыклар, салатлар да ясый, кыяр-помидорын да үзе тозлый. Бәлеш салу да кулыннан килә аның.

– Нәрсәсе бар инде аның? Әле менә Пасхага кулич, дерелдәвек астында кабымлык әзерләгән идем. Тәмле килеп чыкты, – ди ул.

Әле бит ул эшкә дә йөрергә өлгерә. Ике ел Әфганстанда хезмәт итүен, җырлар, шигырьләр язуын, рәсемнәр ясавын да язсак, исемлек шактый саллы килеп чыга. Баштагы уйларны эш басса, күңелдәгесе кәгазь битләренә сибелгән аның. Шактый шәхси булса да: «Үзегезгә ялгызыгызга гына авырдыр. Кабат гаилә корырга уйламадыгызмы?» – дигән сорауны бирмичә түзә алмадык. Җавабы да истә кала торган булды:

– Миңа 60 яшь. Бу вакытка инде һәркемнең тормышка үз карашы, мөнәсәбәте формалашкан. Һәркемнең үзе корган оясы, балалары бар. Һәркемнеке – үзенә. Ни өчен әле мин кемнедер үземнекеләр белән мәшәкатьләргә тиеш?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Менә шулай, Марат абый янына бытбылдыклар турында гына язарбыз дип кергән идек югыйсә. Яңа танышыбызга тәмам сокланып кайтып киттек. Аның белән аралашып, машинага кереп утыргач та, күңелдә әллә нинди бер җылы, рәхәт хисләр калды. Матур кеше белән бер сәгатьтән азрак аралашу да күңелне тутырырлык җылылык, рәхәтлек бирергә сәләтле шул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИШЕКЛӘРЕ БИКЛЕ ТОРМАСЫН

Иман йорты

Шушы көннәрдә Мамадыш районының Түбән Яке авылында өч катлы яңа мәчет ачылды. Авылда 1996 елдан бирле эшләп килүче мәчет бар иде. Авыл имамы шуны төзекләндерү, янына бер корылма өстәп, зурайту турында хыяллана. Дин дәресләренә өйрәнәм дип торучы балалар, җомга намазларына килүчеләр шактый. Авыл депутаты Рифат Мәхмүтовка шул гозер белән мөрәҗәгать иткәч, ул яңаны төзү яхшырак булачак, дигән фикергә килә. Аны авылдашлары да хуплый.

Биш ел буе төзелгән мәчетне ачу тантанасына Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та кайткан иде. Татарстан мөфтие авыл халкын бәйрәм белән котлап, мәчетнең ишекләре бикле тормасын иде, дигән теләген җиткерде. Марат Әхмәтов та, авылның иң матур җирендә урнашкан мәчет үзенә тартып торсын, дигән теләктә.

– Дингә якынаю һәркемгә үз вакыты белән бирелә. Кемдер балачактан дин юлында була, берәүләр олыгаеп кына мәчеткә йөри башлый. Динсез кеше юк. Иртәме, соңмы, кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная. Әмма, минем уйлавымча, иң бәхетлеләр дин юлына баса. Изге юлда булганнарның күңеле чиста була. Сезгә дә шуны телим. Матур мәчетегезгә йөрегез, – диде ул.

Район башлыгы Анатолий Иванов Түбән Якедә ачылган мәчет өчен шатлануын яшермәде.

– Бу – районыбыз өчен зур горурлык, – диде ул. – Сезнең авылда дин көчле. Кечкенәдән балаларны өйрәтәсез. Дөресе дә шул – бала кечкенәдән Аллаһы Тәгаләне белеп үсәргә тиеш. Бервакыт мин районДагы мөселман балаларына дин китаплары өләшеп чыктым. Догалар өйрәнмәсләрме дип тараткан идем. Рус милләтендәгеләргә дә китаплар таратабыз. Шөкер, бездә христиан дине дә, мөселман дине дә бертигез. Шуның белән бәхетле дә без. Төрле милләтләрнең дус булып яшәве, бер-берен хөрмәт итүе, аның гореф-гадәтләрен белүе – үзе зур сөенеч. Татулык нигезе шушы инде. Мин һәр эшемне Аллаһы Тәгаләгә тапшырып башлыйм. Шулай эшләнгән эш һәрвакыт уңа.

Дөрестән дә шулай. Мәчетне төзеткән төп иганәче – Мамадыш икмәк кабул итү пункты җитәкчесе булып эшләүче Рифат Мәхмүтов, эш башлагач, Аллаһы Тәгалә әллә кайлардан җаен бирде, ди.

– Бервакыт район башлыгы белән авылга җыенга килдек. Мәчетне карап чыгарга туры килде. Озак уйладым, искегә тотынганчы, яңаны төзү арзанга чыга дигән фикергә килдем. Иң беренче эш итеп, мәчет салынасы җирнең документларын барлап, эшкә тотындык, – ди Рифат Мәхмүтов. – Мәктәптә укыганда ук авылда мәчет салырга иде дигән уем бар иде. Мин генә салдырдым, дип әйтә алмыйм. Киң күңелле авылдашларым да ярдәм итте. Кемнәр генә матди ярдәм күрсәтмәде. 1 мең сумнан 300 мең сумга кадәр сәдака алып килүчеләр булды. Акчаның тиененә кадәр махсус дәфтәргә теркәп барылды.

Рифат абый, төзелеш вакытында көтелмәгән хәлләр дә булды, ди. Бервакыт эшлекле сәфәргә самолетта очканда янындагы күршесе белән сөйләшеп китә. Нинди эшләр белән йөрүен сөйли. Теге ир-ат Рифат абыйның телефон номерын сорап ала. Берничә көннән картасына, мәчеткә ярдәм дип, 100 мең сум акча килеп төшә. Ә ачылыш алдыннан керү юлына 4 метр да 80 сантиметрлы палас алырга дип кибеткә бара ул. Баксаң, аңа кирәге нәкъ ул аласы үлчәмдә калган икән.

Рифат Мәхмүтовның авыл өчен эшләгән эшләрен санап бетерерлек түгел. Зират коймаларын яңарту да, балалар өчен баскетбол мәйданчыгы да аның ярдәме белән башкарылды. Апасы Әнисә дә энесенең изге күңелле булуы белән горурлана. «Эшләгән эшләрен Аллаһы Тәгалә кабул итсен. Бик ярдәмчел кеше ул. Башкача яши дә алмас иде», – ди апасы.

Түбән Яке авыл җирлеге башлыгы Рафаил Низаметдинов авыл кешеләренең бердәм, дус-тату булулары белән горурлана.

– Әгәр бердәм булмаса, бер эш тә башкарып булмый. Бүгенге чарага әзерләнгәндә дә шуңа инандым. Һәр кеше үзеннән нининдидер өлеш кертергә тырышты. Хатын-кызларыбыз 250 кешегә табын әзерләделәр. Мәчет төзелешенә үзеннән өлеш керткән һәркемгә чиксез рәхмәт, – диде ул.

Мәчеттә беренче намаз ураза аенда, җомга көне укылган. «Шөкер, ай буе тәравихларга йөрдек. Хатын-кызлар өчен аерым бер кат булдырылган. Иман йорты үзенә тартып тора. Күңелләребезне чистартып, Аллаһы Тәгаләгә тагын да якынайсак иде», – ди авыл абыстае Маһинур Гобәйдуллина.

Бу көнне Рифат Мәхмүтов исеме еш телгә алынды. Авыл кешесе аңа бик рәхмәтле. Шуңа да мәчеткә Рифат абыйның әтисе исемен куштылар. «Мәкъсүт» мәчете районда 62 нче мәчет икән. Иске мәчетне Су-Елга авылына күчереп куячаклар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Рухи остаз

Сармашбаш авылы имамы Юныс Ибраһим улы Мортазин бик күпләрне олы юлга әзерләгән мөгаллим дә әле. Ул кырык ел мәктәптә эшләде. Инде хәзер рухи остазыбызга әверелде.

Башта Юныс ага директор урынбасары, мәктәп директоры булды. Балаларга тарих, җәмгыять белеме, хокук белеме, география, биология, татар теле һәм әдәбияты, Татарстан тарихы, «Гаилә этикасы һәм психологиясе» дәресләрен укытты. Үз эшенең чын остасы булып җитлеккән укытучымның хезмәте югары бәяләнде. «Россиянең мәгариф отличнигы», «Россия гомуми белем бирү системасының мактаулы хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәргә лаек булды һәм күп санлы мактау грамоталары белән бүләкләнде. Тора-бара дөньяви белемнән дини белем бирүгә күчте. 2018 елда Сармашбаш авылы мәчетенең имам-хатыйбы итеп сайланды.

Авылдашлар белән Юныс хәзрәтнең мөнәсәбәтләре яхшы, һәр кешегә ярдәм кулы сузарга тора. Өмәләр оештыра, беренче булып үзе эшли, бигрәк тә мәрхүмнәрне соңгы юлга озатканда кешеләр аның ярдәмен тоялар. Нинди генә дини чара үтмәсен, һәрберсендә үгет-нәсыйхәт, дингә өндәү Юныс хәзрәтнең төп эш юнәлеше булып тора. Ул никах уку, балага исем кушу шикелле мәҗлесләрне дә оста итеп оештыра. Әти-әниләргә яңа туган балаларга исем сайларга ярдәм итә. Исемнең кеше тормышында зур мәгънәгә ия булуына басым ясый. Никахларга булган таләпләрне дә үтәргә тырыша. Гаилә корырга әзер булган яшьләр һәм аларның әти-әниләре белән очрашулар үткәрә.

Авыл халкын мәчеткә һәм мәчет эшчәнлегенә тарту өчен үзенең күп көчен куя. Шөкер, намазларга йөрүчеләр саны артты, ә бәйрәм намазларына килүчеләр мәчетне шыплап тутыралар. Рамазан аенда ураза тотучылар, намазга басучылар бермә-бер артты. Сармашбаш мәхәлләсе мәчетендә дә тәравих намазлары даими укыла. Мәчеттә гарәп әлифбасын өйрәнүчеләр саны да артты. Узган уку елында йөрүчеләребез кулларына Коръән алып укый белү бәхетенә ирештеләр.

Юныс хәзрәт – өч бала әтисе, гаиләләре үрнәк, тату. Эш сөючән бу гаиләнең уңганлыгын ерактан ук матур булып балкып торган төзек, чиста йортҗирләре дә күрсәтә. Юныс хәзрәт тирә-якка билгеле оста умартачы да әле. Теләге булган авылдашларына да бу төр хезмәтнең серләренә төшендерә. Тагын бер асыл сыйфаты – мохтаҗларга ярдәм итү. Аның үрнәгендә башка гаиләләр дә өлкән яшьтәге авылдашларына ярдәм итеп яшиләр.

Алсу ГЫЙНИЯТУЛЛИНА.
Зәй районы Сармабаш авылы

ҮТКӘНЕҢНЕ БЕЛМӘСӘҢ...

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк! Бу сүзләр – Камил хәзрәтнең яшәү девизы. Иң беренче мулла турында мәгълүмат туплап, ул яшәгән йортка истәлек тактасы элүне оештырды. Зиратларда яз-көз өмәләр оештырып, кешеләрне вәгазьли. Авыл халкы елдан-ел мәчеткә тартыла. Болар шуңа дәлил түгелмени?

Габделгали улы Камил Абдуллин Кече Урыссу авылында сигез балалы гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Яхшы билгеләргә мәктәпне тәмамлагач, техникум, институт белеме алып, нефть өлкәсендә эшли. Себер якларыннан Лениногорск шәһәренә кайтып төпләнгәч, күңеле туган авылына тартканлыктан, авылда йорт төзи. Шул елларда авылыбызда мәчет төзелә. Колхоз рәисе аңардан: «Мәчет манарасына гөмбәзе белән ай кайтарып булмасмы?» – дип ярдәм сорый. Ул бу эшне бик теләп башкарып чыга. Мәчетне ачу тантанасына Камилнең үзен дә кунак итеп чакыралар. Авылда азан тавышы еракка-рак яңгырасын дигән теләктән чыгып, ул мәчеткә тавыш көчәйткеч бүләк итә. Лениногорск мәчетендә гарәпчә укырга, язарга өйрәнеп йөргән көннәре булса да, намаз әһеле булса да, туган авылында имам булырмын дип башына да китерми ул. Авылга кайтып төпләнгәч, элекке мулла, олыгаю сәбәпле, аны үз урынына кодалый башлый. Камил Урыссудагы «Фәнис» мәдрәсәсенә укырга кереп, диплом ала һәм имамлык эшенә керешә.

Хәзрәт – район күләмендә үткәрелгән чараларның, мәктәптә узган семинарларның, ачык дәресләрнең хөрмәтле кунагы. Ул – республикада үткән чараларның да актив катнашучысы, Казан шәһәрендә «Мөселман уку йортлары укытучылары форумы» район делегациясе әгъзасы.

Авыл Сабантуйларында, балалар бакчасында һәм мәктәптәге чараларда катнаша, сугыш һәм тыл ветераннарын туган көннәре белән котлый һәм истәлекле бүләкләрен тапшыра. Һәр ел саен мәчетебездән делегация Изге Болгар җыенында катнаша.

Һәр иртә Камил хәзрәтнең әйткән азаны авылыбызга иман нуры сибә. Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәмнәре дә авыл халкы белән зурлап уздырыла. Рамазан аенда тәравих намазлары укыла, ифтар мәҗлесләре оештырыла. Җомга көнне укылган вәгазьләр дә рухи тәрбия чыганагы булып тора. Аллага шөкер, авылыбыз иманлы, хуҗалы. Сөбханаллаһ!

Аллага шөкер, мәчетебездә дини гыйлем алырга теләүчеләр елдан-ел арта. 2021–2022 нче уку елында мәчеттә 4 төркем хатын-кыз, бер төркем балалар гыйлем ала. Үзебезнең авылдан гына түгел, хәтта күрше авыллардан да дин нигезләрен өйрәнергә йөриләр.

Изге йортыбыз янында, киләчәктә балаларны мәчеткә тагын да якынайту максатыннан һәм ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан балалар мәйданчыгы төзелеп килә. Күздән үк мәйданчык, төрле төстәге коймалар белән уратып алынып, агачлар утыртылды, бүген эчен җиһазландыру тәмамланып килә.

Узган җәйне авылыбызда чишмә барлыкка килде. Аны төзекләндерү идеясе дә – Камил хәзрәтнеке. Ул аңа әнисе хөрмәтенә «Зәйтүнә» исемен бирә.

Агач утырту – Җир йөзендә үз эзеңне калдыру өчен менә дигән мөмкинлек. Тирә-яктагы югалган авылларның (Чик-Бүләк, Баланлы) зиратларын төзекләндерү, авыллар булган урыннарга истәлекле ташлар куйдыру эшләре дә Камил хәзрәт җитәкчелегендә тормышка ашырыла.

Авылыбызда бер генә чара да хәзрәтебез фатихасыннан башка башланмый. Бигрәк тә язгы чәчүне Азан әйтеп, Коръән аятьләре укып башлап җибәрү традициягә әйләнеп килә.

Шәхсән, мин үзем, Камил белән башлангыч классларда бер мәктәптә укыдым. Аның гаиләсе белән балачактан аралашып, бергә уйнап үстек. Хәзер олыгайгач кына аңлыйм: нинди акыллы, олы йөрәкле, сабыр холыклы булган бит Зәйтүнәттәй! Үзенең 8 баласы өстенә безне, күрше-күлән балаларын да, сыендырып, тәмле теле белән безнең күңелләрне җылыткан. Ул бит безнең барыбызны да яратып, «алма бөкәләрем» дип йөртә иде… Урыны җәннәттә булсын! Амин!

Камилләрнең гаиләсе бик тату, дус, динле. Һәрбер туганы белемле, кешелекле, җитәкче урыннарда эшлиләр. Камилнең кечкенә чагын искә алып, хәзерге вакытын күзәтәм дә күңелемә шундый сүзләр килә: Камил хәзрәт – туган як каеннарыдай горур, имәндәй нык ихтыяр көченә ия, һәр кылган гамәле белән гомер юлларын бизәп, намус, вөҗданны юлдаш итеп яшәүче соклангыч зат. Киләчәктә дә ныклы саулык, яхшы кәеф, яшәү дәрте өстәрлек уңышлар, Рәзинә абыстай белән озак еллар парлашып, «кайнар чәй» эчеп яшәргә язсын.

Кече Урыссуның ал таңнары синә
Бүләк иткән күңел аклыгын.
Юлдаш итеп сайлагансың яшьтән
Чылтырап аккан чишмә сафлыгын.
Вөҗдан күзе белән карыйсың син
Тормыштагы һәрбер мизгелгә.
Күпме изге гамәл энҗе булып,
Гомер юлыңа синең сибелә.
Рухың ныклыгына таянасың,
Нәкъ меңьяшәр имән төсле син.
Чор сулышын ачык тоемлаучы
Зыялы һәм затлы кеше син!

Вәсилә ИЛЬЯСОВА.
Ютазы районы Кече Урыссу авылы

Көрәшче Нургаяз

Яшь чагында көчле көрәшче була, бик күп ярышларда җиңү яулый. Үз авырлыгында Муса Җәлил призына оештырылган ярышта чемпион исемен ала. Сүзем – безнең авыл имамы Галиуллин Нургаяз Әсхәт улы турында.

1968 елның 9 апрелендә бормаланып аккан Сон елгасы буена урнашкан, илгә талантлы композиторлар Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннарны биргән Мамадыш районы Кече Сон авылында дөньяга килә ул. Туган авылында башлангыч белем ала, күрше авылга йөреп, урта мәктәп тәмамлый.

Бик күп яшьләр шикелле, читкә чыгып китеп, бәхетен дә эзләп карый Нургаяз. 16 ел Түбән Кама шәһәрендә шофер булып эшли. Шул чорларда ул дин юлына баса, мәчеткә йөри башлый. Ләкин туган як, туган нигез аны кире чакырып кайтара. Аннары Мамадыш мәдрәсәсен тәмамлый, дингә ныклап керешеп китә.

Гаиләсе дә авылга үрнәк. Хатыны Гөлгенә белән дүрт бала тәрбияләп үстерделәр, инде онык сөяләр. Балалары барысы да дин юлында. Икенче кызлары Гөлфинә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлады, олы малайлары Мөхәммәтнур Мамадыш мәдрәсәсендә белем алды. Кече уллары Йосыфның ахшам намазына чакырып азан әйтүе күңелнең барлык кылларын тибрәтә, йөрәккә үтеп керә. Безнең авылда биш вакыт намазга да азанны мәчеткә йөрүчеләр әйтә.

Авылыбызны ямьләндерү, төзекләндерү эшендә дә башлап йөри имамыбыз. Аның тәкъдиме белән авыл уртасындагы чишмә янында чәчәк түтәлләре ясалды, җәй көне андагы төрле төстәге чәчәкләр җанны иркәли, күңелгә тынычлык бирә.



Берничә ел хыялланып йөргәннән соң, авыл зиратына таш юл түшәтү бәхетенә дә ирешә ул. Ел саен май ялларында зиратны чистарту өмәсе оештырыла, монда да башлап йөри хәзрәтебез.

Мәңгелек йортыбызны тимер койма белән әйләндереп алуга да мәчет матди ярдәм күрсәтте. Өмә ясап, матур итеп оештырылды бу чара.

Мәчетебез тыштан да, эчтән дә нур чәчеп тора. Анда газ кергән, җылы су бар. Ирләр, хатын-кызлар өчен тәһарәтханәләр ясап куелды. Әйләнә-тирәсен тимер койма белән әйләндереп алуга авылыбыздан чыккан, Түбән Камада яшәүче иганәче егетебез Азат Билалов булышлык күрсәтте. Җәй көне Аллаһ йорты шау чәчәккә күмелә.

Авыл халкын дингә, мәчеткә тарту буенча да күп эш башкара Нургаяз хәзрәт. Мамадыш мәчетеннән, Казаннан дәрәҗәле дин әһелләре чакырып даими рәвештә вәгазь дәресләре үткәреп тора. Авылда намаз укымаган кеше сирәк. Гает намазларында Аллаһ йортына бик күп кеше җыела. Көндәлек намазларга да уннан артык кеше йөри. Рамазан аенда мәчеттә ифтар ашлары уздырыла. Тәравих намазына кырыктан артык кеше йөрү дә имамның абруе, халыкның дингә тартылуы, ышанычы турында сөйли.

Мәдрәсә тәмамлаган абыстайлар берничә төркем оештырып, хатын-кызларга, балаларга дин дәресләре бирәләр, гарәпчә укырга өйрәтәләр. Шушы төркемнәргә йөрүче шәкертләр берничә ел рәттән районда оештырылган Коръән укучылар бәйгесендә призлы урыннар яулыйлар.

Аннары тагын хәзрәтнең бер сыйфатын әйтеп китмичә булмый. Авылда эчкечелек көчле булмаса да, аек авыл өчен дә көрәшә Нургаяз, халыкны хәләл ризык белән генә тукланырга өнди. Авылда калучы яшьләр булмаганга, балалар саны кимегәнгә дә бик борчыла имамыбыз. Намазлардан соң ул: «Авылда эш булып, яшьләребез авылда калса иде, матур авылларыбыз балалар тавышыннан яңгырап торса иде», – дип тели.

Ләйсирә ЯРУЛЛИНА.
Мамадыш районы Кече Сон авылы

ТАЯНЫЧЫМ ДА, ГОРУРЛЫГЫМ ДА – БАБАМ

Әлеге бәйгедә үземнең яраткан бабам Зарипов Дамир Хатыйп улы турында язарга булдым. «Ватаным Татарстан» – безнең гаиләнең яраткан газетасы. Аның һәр номерын көтеп алабыз. Бигрәк тә бабам бик ярата! Ул күп еллар үзебезнең авылда авыл имамы вазыйфасын үти. Дәү әнием белән икәүләшеп алар һәр язманы җентекләп, үзара бәхәсләшеп укыйлар. Ә җомга көнне чыккан санның урта битен аерып, җыеп та баралар.

Язганымча, бабам авылыбызда имам вазыйфасын үти. Аңа 81 яшь. Олы яшьтә булуына карамастан, ул тормышны яратып, ямен тоеп, шатланып яши. Биш вакыт намазын калдырмыйча укый. Йорттагы мал-туарны да карарга булыша. Дөньядагы хәлләрне дә җентекләп күзәтеп бара. Авылдагы бер вакыйгада аның катнашыннан башка үтми. Авылда ул зур хөрмәткә ия кеше!

Бабамның хезмәт юлы да, тормышы да туган авылында узган. Ул чит җирләрдә бәхет эзләп йөрмәгән. Гади авыл механизаторы булып көн күргән. Кырык биш ел хезмәт стажы белән лаеклы ялга чыккан. Аның фотосы «Үрнәк» колхозының мактау тактасыннан төшмәгән, ул һәрвакыт алдынгылар рәтендә булган. Безнең гаиләдә аның грамоталары, рәхмәт хатлары саклана.

Минем бабам тырыш хезмәте өчен атказанган колхозчы исеменә лаек була. Әти-әнисеннән өйрәнгән догаларны ул тракторда эшләгәндә дә, комбайн йөрткәндә дә гел кабатлаган. Тора-бара Коръән сүрәләрен өйрәнгән. «Тормышта төрле хәлләр булды. Сынауларны үтәргә Аллаһы Тәгалә ярдәм итте», – дип кабатларга ярата бабам. Алар дәү әнием белән нык гаилә төзегәннәр, матур-матур балалар үстергәннәр. Ә хәзер безгә – оныкларына яхшы кеше булып үсәргә булышалар.

Авылны яңгыраткан азан авазын ишетү – зур шатлык! Димәк, авыл яши, аның киләчәге бар дигән сүз. Ә бит бүген күпме авыл ташландык хәлдә, күпмесе юкка чыкканнар исемлегендә. Ә минем кечкенә генә Татар Аксуында тормыш гөрли. Мин моңа бик сөенәм. Минем бабам кебек имамнар булганда яшьләргә юл күрсәтүче кешеләр бар, димәк.

Ләйлә ЗАРИПОВА, 15 яшь.
Буа районы Татар Аксуы авылы

Сабан туен көткәндә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сөлгеләрне сөлгеләргә ялгап...

Быел Казан Сабан туе 17 июньдә – сөлге җыю бәйрәме белән башланып, 19 июньдә көрәш батырын ачыклау белән тәмамланачак.

Татарстан башкаласында узачак бәйрәмнең быелгы үзенчәлекләре турында Казан Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов «Эшлекле дүшәмбе» вакытында сөйләде.

17 июнь. Бу көнне 11.00 сәгатьтә Казанның үзәк урамнарыннан уза торган махсус маршрут буенча, йоласына туры китереп, Сабан туена сөлге, бүләкләр җыячаклар. Сөлге җыю Камал театры янындагы мәйданда концерт программасы белән тәмамланачак.

18 июнь. 16.30 сәгатьтә Казан ипподромында традицион ат чабышлары башланачак. Барлыгы 14 чабыш булыр дип көтелә. Шулай ук бу көнне кунакларны концерт программасы һәм бүләкләр уйнату да көтә. Бәйрәм салют белән төгәлләнәчәк.

19 июнь. Күңел ачулар Тынычлык бистәсендәге Каенлык, Дәрвишләр бистәсендә һәм Аккош күлендә дәвам итәчәк. Бәйрәм чаралары 9.30 сәгатьтә башлана.

Беренче мәйданчыктагы бәйрәм татар яшьләренең борынгы йоласы – утырма белән башланып китәчәк. Монда шулай ук татар эстрадасы йолдызларының чыгышы да көтелә.

Дәрвишләр бистәсе һәм Аккош күлендә дә танылган җырчылар чыгыш ясаячак. Татарстанның иң көчле көрәшчеләре дә шушы көнне ачыкланачак. Төп батырга тәкә һәм квадроцикл тапшырылачак.

Сабан туе мәйданчыклары 16.00 сәгатькә кадәр эшләячәк.

НИЧЕК БАРАСЫ?

Кунаклар өчен махсус автобус маршрутлары оештырылачак, шәһәрдә өлешчә юл хәрәкәте схемасы үзгәрәчәк.

Тынычлык бистәсендәге Каенлыкка махсус автобуска дүрт тукталыштан утырып китәргә мөмкин. Болар – «Җиңү проспекты станциясе», «10 нчы микрорайон», «Филармония концертлар залы» һәм «Глазунов урамы» (Теплоконтроль) тукталышлары. Моннан тыш, Каенлыктагы Сабан туена «Казан-1» станциясеннән 23 нче һәм 56 нчы номерлы электр поездында килергә мөмкин булачак.

Аккош күленә Компрессор заводы һәм «Мега» сәүдә үзәге яныннан узачак автобусларда, шулай ук 1, 25, 24, 60, 84, 91 нче номерлы шәһәр автобусларында барып җитәргә мөмкин булачак.

ЧАЛЛЫ

Чаллыда да бер көн белән генә чикләнергә уйламыйлар. 17 июньдә мөмкинлекләре чиклеләр өчен бәйрәм уздырырга җыеналар. Икенче көнне исә кунакларны «Яр буе» паркында көтәләр. Кичен монда Татарстанның халык артисты Гүзәл Уразова чыгыш ясаячак.

ТҮБӘН КАМА

Сабантуй инде бу атнада – 11 июньдә узачак. Бәйрәм чаралары 9.00 сәгатьтә башлана. Түбән Кама Сабан туеның үзенчәлеге – районның 15 авыл җирлеге вәкилләре кунакларга «Минем авылым» дип аталган тематик интерактив мәйданчыкны тәкъдим итәчәк. Халыкның күңелен Фирдүс Тямаев белән Илсөя Бәдретдинова күрәчәк.

* * *

Сабантуйларны Башкортстанның 18 районында уздырырга өлгергәннәр инде. 4 июньдә Самара халкы да бәйрәм иткән. 5 июньдә исә милли бәйрәмне Новосибирскида яшәүче милләттәшләребез дә үткәргән.

Алда әле бәйрәмнәр тагы да көтелә. Исегезгә төшерәбез: Татарстан авылларында, район үзәкләрендә бәйрәм 11–13 июньдә узачак. 17–18 июньдә Ульян өлкәсендә – Федераль Сабан туе, 2 июльдә Мордовиянең Аксен авылында Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе үткәреләчәк.

СЫЙЛЫ БӘЙРӘМ

ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫНЫҢ КАДРӘК АВЫЛЫНДА РЕСПУБЛИКАКУЛӘМ СЕМЫК УЗДЫ

Әгерҗе

Семык – мариларның иң яраткан бәйрәмнәренең берсе. Ул җәйне каршы алуны да, якты дөньядан киткәннәрне хөрмәтләүне дә чагылдыра. Мариларның җир эшкәртү, авыл хуҗалыгы, гаилә мөнәсәбәтләре һәм башкалар белән бәйле бик күп традицияләрен һәм йолаларын үз эченә ала ул.

Кадрәк авылында узган Семык бәйрәмендә көне буе диярлек тоташтан яңгыр яуды. Әмма ул бәйрәмнең ямен дә бетермәде, халыкның кәефен дә төшермәде. Семык булачак мәйданга халык иртән иртүк килә башлады.

– Узган ел Семык безнең районда гөрләгән иде. Бирегә «Ший памаш» фольклор халык ансамбле вәкилләре белән бергәләп килдек. Элек ансамбльгә без дә йөрдек. Хәзер урыныбызны яшьләргә бирдек, – диделәр Актаныш районыннан килгән Галина Михайлова белән Тамара Солтангалина. – Безгә һава торышының нинди булуы мөһим түгел. Яңгыр яуганга артык борчылмыйбыз. Ходай Тәгалә үзе белеп бирә ул.

Кунаклар Семык аллеясына агач та утырттылар.

– Бездән матур истәлек калсын әле, – диделәр Балтач районы Улисьял авылыннан килгән делегация вәкилләре.

Шул рәвешле, бәйрәмгә бер-бер артлы республиканың Актаныш, Арча, Балтач, Алабуга, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим районнарыннан, Казан, Түбән Кама, Чаллыдан, Мари Иле, Удмуртия, Башкортстаннан, Свердлау өлкәсеннән, Алтай краеннан делегацияләр килде. Әлбәттә, бәйрәмне кабул итүче Әгерҗе районы делегациясе сан ягыннан иң зурлардан булгандыр.

Кунаклар мари, рус, татар, удмурт, чуаш ишегалларын кереп күрде. Әгерҗе районының тарихы һәм бүгенгесе белән танышты. Шунда ук мариларның ачык һавада урын алган мичтә пешерелгән милли ризыклары – «коман мелна»дан (безнеңчә әйтсәк, белен) да авыз итәргә була иде. Кунаклар Чирмешән районыннан килгән чуаш вәкилләре янында тукталып, үзенчәлекле мастер-классны күзәттеләр. Асылы бик тә гади: махсус зур иләк ярдәмендә бодайны иләп, юып, киптереп, ярма ясап, шунда ук ботка пешерәләр. Табигый ризыктан авыз итүчеләр дә күп булды.

Бәйрәмне башлап җибәрү өчен сәхнәгә Татарстан мариларының милли-мәдәни автономия җитәкчесе, республиканың баш карты (рухи җитәкчесе) Олег Третьяков күтәрелде. Бәйрәм әләмен Кадрәкнең хөрмәтле кешеләре – Виталий Савельев, Анна Асылбаева һәм «Кадрек сем» ансамбле вәкилләре күтәрде. Бәйрәмнең рәсми өлешен район башлыгы Азат Вәлиев ачты.

– Әгерҗе районында төрле милләт һәм дин вәкилләре дус һәм тату гомер кичерә. Шулар арасында хезмәт сөючән мари халкының да лаеклы урыны бар. Алар халык хәтерен, матур традицияләрен, җыр-биюләрен саклап яшиләр, спорт өлкәсендә зур уңышларга ирешәләр, – диде район башлыгы. – Ә бүгенге яңгырга иген үстерүчеләр бары тик сөенергә тиеш. Җылы җәйге яңгыр – яхшы уңыш нигезе ул.

agryz-rt.ru

Премьер-министр урынбасары Роман Шәйхетдинов – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның, Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау сүзләрен җиткерде.

– Семык бәйрәме республикабызда 1990 елдан бирле зурлап билгеләп үтелә. Ә быелгысы Халык сәнгате һәм мәдәни мирасны саклау елында узуы белән үзенчәлекле. Бүген һәркайсыбызның үзен күпмилләтле бердәм Россия мәдәниятенең һәм халык тарихының бер өлеше итеп тою мөмкинлеге бар, – диде Роман Шәйхетдинов.

– Әгерҗе районы – Татарстанның иң матур төбәкләренең берсе. Биредә иң зур елгалар, урманнар урнашкан. Мариларның балы – иң тәмлесе. Марилар – хезмәт сөючән халык. Һәр халык менә шулай телен, традицияләрен сакласын иде. Бу шулай булсын өчен барыбыз да тырышырга тиеш, – дип теләде Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов.

«Семык бәйрәме – халык рухы хәзинәсе» дип аталган театральләштерелгән күренеш бәйрәмнең иң матур һәм иң истәлекле өлеше булды. Ул Кадрәк авылының тарихын бәян итеп кенә калмыйча, чыгыш ясаучылар тамашачыга мари халкының традицияләрен һәм көнкүрешен, аларга хас табигатьне ярату, киң күңеллелек, кунакчыллык кебек сыйфатларын да күрсәтте.

Бәйрәмгә җыелган халыкның күңелен республика районнарыннан, Россия төбәкләреннән килгән иҗат коллективлары күрде. Аларны тамаша кылганда да, «Мари Иле» дәүләт бию ансамбленең дәртле, матур чыгышларын караганда да халык рәхәтләнеп биеде, кушылып җырлады. Михаил Веселов һәм Лилия Петухова иҗат коллективы катнашындагы күңел ачу программасы бәйрәм киченә нокта куйды.

Көнозын яуган яңгыр спорт ярышларын уздыруга да киртә була алмады. Үзләрен чаңгыда узышу, гер күтәрү, утын кисү, чүлмәк вату кебек ярышларда сынаучылар булды. ГТО нормаларын үтәү мәйданчыгы эшләде. Шулай да иң үҗәтләре, чыдамнары волейболчылар булгандыр, мөгаен. Алты команда арасында ярыш бик кызу барды. Нәтиҗәдә беренче-өченче урыннарны Мадык, Сарсак-Омга, Тирсә волейболчылары алды.

Семык бәйрәме июнь аена билгеләнсә дә, марилар аңа узган ел ук әзерләнә башладылар. Уртак тырышлык белән бер-бер артлы бәйрәм капкасы, җил тегермәне, кунакчыл мари ишегалды, хәтта күперле ясалма күл барлыкка килде. Бергәләп юлларны тәртипкә китерделәр, эскәмияләр, өстәлләр, кече сәхнәләр, балалар мәйданчыгы ясадылар. Соңгы вакытларда, йокыларын да онытып, бергәләп милли ризыклар әзерләделәр. Бәйрәм көнне казаннарда ризык пеште, чәй кайнады. Бердәмлек, тырышлык, кунакчыллык бәйрәме булды ул. Киләсе елда да республикакүләм Семык Әгерҗе районында узачак. Бу юлы – Бима авыл җирлегенә караган Пеләмеш авылында.

Дания АБЗАЛИЕВА

БИЕГӘН КЕШЕ БАЙ БУЛА!..

КАЗАН ХАЛКЫН «ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ» ОСТАХАНӘЛӘРЕНӘ ЧАКЫРАЛАР

Халык биюләрен сәхнәдән генә кем дә карап утыра ала ул. Бер сәгать буе «Ярмәк вагы»на басып кара син! «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектының җәйге остаханәләре нәкъ менә шул биюне өйрәнүдән башланды. 500ләп кеше Кабан күле буендагы агач идәннәрнең ныклыгын тикшерде.

Әллә һава торышының җайлануы, әллә спортлы-иҗатлы «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектының популярлыгы, әллә халыкның биюгә сусавы шулай тәэсир иткән – болай да кеше белән «кайнап» торган Кабан буена халык агылды да агылды. Яңа гына тәпи киткән сабыйлардан башлап, таякка таянган әби-бабайларга кадәр бар иде анда.

Әйткәнебезчә, ул кичне теләгән һәркемне «Ярмәк вагы» халык биюенә өйрәттеләр. Бу биюнең тарихы болайрак: Самара өлкәсенең Ярмәк авылы егетләре армиягә китәр алдыннан җыелышып күңел ача торган булган. Биюләрсез дә булмаган. Ләкин гади генә бию булмаган ул. Берсе икенчесенең аяк астына чыбыркы белән суккан, икенчесе шуңа басарга тырышкан. Шул рәвешле тыпырдау килеп чыккан. Элек «Ярмәк вагы»на егетләр генә басса, тора-бара яшь кызлар да бии башлаган. Моны безгә Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты Владислав Уткин сөйләде. Алар бу биюне Самарадагы «Ак каен» ансамбле җитәкчесе Наил Галимуллиннан отып калган икән.

Шәһәр халкы өчен бию дәресен Владислав белән беррәттән педагог-хореограф Сәидә Миңнебаева, фламенко биюе остасы Гөлсинә Галимуллина, «Казан» бию ансамбле солисты Рамазан Җамалетдинов үткәрде. «Татар биюен бер урында тыпырдау белән чикләнә дип уйлый күрмәсеннәр иде», – ди биючеләр. Шуңа да халык биюенең үзенчәлекләре, сез һәм без белмәгән хәрәкәтләре белән таныштырырга ниятлиләр.

kzn.ru

Узган җәйдә «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты кысасында 14 чара узган. Аларда барлыгы 550 кеше катнашкан. Очрашулар Кабан күле буеннан тыш, «Ак чәчәкләр» һәм Фучик бульварларында, Горький һәм Урицкий паркларында, «Черек күл»дә узган. Проектның юнәлешләре арасында йога, сулау практикалары, спорт, биюләр бар.

Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, әлеге проектны башлап җибәрүче Гүзәл Сәгыйтова әйтмешли, татар биюе, татар теле тантана иткән шушы кечкенә бәйрәмнең дә әһәмияте шактый. «Үзегез дә күрәсез: биючеләр дә, күзәтүчеләр дә бик күп. Димәк, халыкка бу кызык һәм кирәк. Остаханәләрдә катнашучыларның төрле яшьтә булуы да сөендерә. Өлкәннәр генә килсә, яшьләр кызыксынмый, дияр идек, яшьләр генә җыелса, шулай ук аудиториябез тар тоелыр иде. Бүгенге дәрес һәм, гомумән, бу проект татарларның биемичә яши алмавын кабат раслый», – дип сөйләде ул. Элегрәк су буйларын шау-гөр китергән кичке уеннарны «терелтергә» кирәк безгә. Гүзәл Сәгыйтова әнә шундый фикер-теләге белән дә уртаклашты. Яхшы булыр иде ул, шулай бит?

Янә «Ярмәк вагы»на әйләнеп кайтсак, җиде түгел, сигезенче кат тирне чыгара торган дәртле бию булып чыкты ул. Сәхнәдән биегәннәрен карап тору, ай-һай, ансат икән. Ә баса башласаң, туктап булмый. Арыганнарың да онытыла, кәефең дә яхшыра. Түгәрәкләнә дөньясы да. Менә шундый бию бүләк иткән безгә Самарада яшәүче милләттәшләребез.

Самара, димәктән, чарага килүчеләр арасында «Ярмәк вагы»ның шушы рәвешле яшәвен, халык арасында шулкадәр зур кызыксыну уятуын күреп, күз яшьләрен тыя алмаган бер ханым да бар иде. Самарада яшәүче Альбина Шәмсетдинова Татарстан башкаласына эшләре буенча килгән була. Ә Кабан буендагы бу чараны, гомумән, очраклы рәвештә, узып барышлый гына күреп, дөресрәге, ишетеп ала. «Кабан күле буена «Ярмәк вагы»ның көен ишетеп төштем. Шунда ук күңелем тулды, ирексездән елый башладым. Бу биюне шулкадәр оста итеп биюләрен, алай гына да түгел, халыкка өйрәтүләрен күргәч, шундый сөендем. Ярмәк авылыннан чыккан бию – Казан, татар үзәгендә! Аны шулай актуаль һәм популяр итүләре өчен мең рәхмәтле мин», – дип сөйләде ул безгә.

«Ярмәк вагы» Самара өлкәсендә бүген дә популяр икән. «Туйларда, яшь егетләрне армия сафларына озатканда, гомумән, мәҗлесләрдә әле дә бииләр аны. Ярмәкнең үзендә аеруча популяр ул. Сәхнәгә чыгып кына түгел, бар халык бергәләп бии «Ярмәк вагы»н», – диде Альбина ханым.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты кысасындагы чаралар июньнән алып сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Ачык һавадагы бушлай остаханәләргә теләгән һәркем килә ала. Киләсе очрашу 15 июньдә, шулай ук Кабан күле буенда узачак. Бу юлы Камал театры артистлары чечетка биергә өйрәтәчәкләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 279

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+